Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылында гражданнар җыены карары

3 декабрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2022 елда Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Бик-Үти авылында юлларны ремонтлауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Бик-Үти авыл җирлегенең Бик-Үти авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Бик-Үти авыл җирлеге башлыгы __________ Р.З. Җәләлетдинов

Халык җыены секретаре __________ Р.С. Гыйззәтова